**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Об отдельных вопросах государственной регистрации, официального опубликования и вступления в силу нормативных правовых актов республиканских органов исполнительной власти, обеспечения в Республике Татарстан единства правового пространства Российской Федерации и о признании утратившими силу отдельных указов Президента Республики Татарстан

Во исполнение Указа Президента Российской Федерации от 10 августа 2000 года № 1486 «О дополнительных мерах по обеспечению единства правового пространства Российской Федерации» **постановляю:**

1. Нормативные правовые акты республиканских органов исполнительной власти, в том числе акты, содержащие сведения, составляющие государственную тайну, или сведения конфиденциального характера, направляются республиканскими органами исполнительной власти на государственную регистрацию в Министерство юстиции Республики Татарстан в течение трех рабочих дней со дня их подписания.

2. Порядок государственной регистрации нормативных правовых актов республиканских органов исполнительной власти, их официального опубликования и вступления в силу определяется Кабинетом Министров Республики Татарстан.

3. Нормативные правовые акты республиканских органов исполнительной власти, не прошедшие государственную регистрацию, а также зарегистрированные, но не опубликованные в установленном порядке, кроме актов и отдельных их положений, содержащих государственную тайну или сведения конфиденциального характера, не влекут правовых последствий, как не вступившие в силу, и не могут служить основанием для регулирования соответствующих правоотношений, применения санкций к гражданам, должностным лицам и организациям за невыполнение содержащихся в них предписаний.

4. Копии нормативных правовых актов Республики Татарстан и сведения об источниках их официального опубликования представляются в Управление Министерства юстиции Российской Федерации

по Республике Татарстан для включения в федеральный регистр нормативных правовых актов субъектов Российской Федерации посредством единой межведомственной системы электронного документооборота Республики Татарстан в семидневный срок со дня первого официального опубликования указанных актов в формате согласно установленным федеральным законодательством требованиям.

В Управление Министерства юстиции Российской Федерации по Республике Татарстан для включения в федеральный регистр нормативных правовых актов субъектов Российской Федерации представляются:

копии законов Республики Татарстан и нормативных правовых актов Президента Республики Татарстан – Аппаратом Президента Республики Татарстан;

копии нормативных правовых актов Кабинета Министров Республики Татарстан – Аппаратом Кабинета Министров Республики Татарстан;

копии нормативных правовых актов республиканских органов исполнительной власти – Министерством юстиции Республики Татарстан;

сведения об источниках официального опубликования нормативных правовых актов, указанных в настоящем пункте и абзаце третьем пункта 5 настоящего Указа, – Министерством юстиции Республики Татарстан.

5. Предложить Государственному Совету Республики Татарстан представлять посредством единой межведомственной системы электронного документооборота Республики Татарстан:

копии законов Республики Татарстан в электронном виде в формате doc или docx в Аппарат Президента Республики Татарстан при направлении указанных законов на подписание Президенту Республики Татарстан;

копии постановлений Государственного Совета Республики Татарстан, имеющих нормативный характер, в Управление Министерства юстиции Российской Федерации по Республике Татарстан для включения в федеральный регистр нормативных правовых актов субъектов Российской Федерации в семидневный срок со дня первого официального опубликования указанных постановлений в формате согласно установленным федеральным законодательством требованиям.

6. Кабинету Министров Республики Татарстан в 30-дневный срок привести свои акты в соответствие с настоящим Указом.

7. Признать утратившими силу:

Указ Президента Республики Татарстан от 8 мая 2002 года № УП-352 «О едином банке нормативных правовых актов Республики Татарстан»;

Указ Президента Республики Татарстан от 25 ноября 2002 года № УП-1031 «О внесении изменений в Указ Президента Республики Татарстан «О едином банке нормативных правовых актов Республики Татарстан»;

Указ Президента Республики Татарстан от 7 сентября 2005 года № УП-361 «О внесении изменения в Указ Президента Республики Татарстан «О едином банке нормативных правовых актов Республики Татарстан»;

Указ Президента Республики Татарстан от 9 января 2007 года № УП-1 «О внесении изменений в Указ Президента Республики Татарстан «О едином банке нормативных правовых актов Республики Татарстан»;

Указ Президента Республики Татарстан от 26 декабря 2008 года № УП-687 «О внесении изменения в Указ Президента Республики Татарстан «О едином банке нормативных правовых актов Республики Татарстан»;

Указ Президента Республики Татарстан от 10 августа 2013 года № УП-751 «О внесении изменения в Указ Президента Республики Татарстан «О едином банке нормативных правовых актов Республики Татарстан»;

Указ Президента Республики Татарстан от 6 марта 2015 года № УП-247 «О внесении изменений в Указ Президента Республики Татарстан «О едином банке нормативных правовых актов Республики Татарстан»;

пункт 1 Указа Президента Республики Татарстан от 8 июля 2016 года № УП-585 «О внесении изменений в отдельные указы Президента Республики Татарстан».

8. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** — **Р.Н. Минниханов**

Казань,Кремль
28 сентября 2017 года
№ УП-861

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын дәүләт теркәвенә алу, рәсми рәвештә бастырып чыгару, аларның үз көченә керүе, Татарстан Республикасында Россия Федерациясе хокукый мәйданы бердәмлеген тәэмин итүнең аерым мәсьәләләре һәм Татарстан Республикасы Президентының аерым указларын үз көчен югалткан дип тану турында**

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе хокукый мәйданы бердәмлеген тәэмин итү буенча өстәмә чаралар турында» 2000 елның 10 августындагы 1486 номерлы Указын үтәү йөзеннән **карар бирәм:**

1. Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актлары, шул исәптән дәүләт сере булган мәгълүматлары яки конфиденциаль характердагы мәгълүматлары булган актлар дәүләт теркәвенә алу өчен республика башкарма хакимият органнары тарафыннан аларга кул куйган көннән өч эш көне эчендә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелә.

2. Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын дәүләт теркәвенә алу, аларны рәсми бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгели.

3. Республика башкарма хакимият органнарының дәүләт теркәвенә алынмаган, шулай ук теркәлгән, әмма билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарылмаган норматив хокукый актлары, дәүләт сере булган мәгълүматлары яки конфиденциаль характердагы мәгълүматлары булган актлардан һәм аларның аерым нигезләмәләреннән тыш, үз көчләренә кермәгән буларак, хокукый нәтиҗәләргә китерми һәм тиешле хокукый мөнәсәбәтләрне җайга салу, алардагы күрсәтмәләрне үтәмәгән өчен гражданнарга, вазыйфаи затларга һәм оешмаларга карата санкцияләр куллану өчен нигез була алмый.

4. Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары күчермәләре һәм аларның рәсми басылу чыганаклары турындагы мәгълүматлар, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актлары федераль

регистрына кертү өчен, әлеге актларның федераль законнарда билгеләнгән таләпләргә нигезләнгән форматта рәсми басылып чыккан көненнән җиде көн эчендә Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнеше бердәм ведомствоара системасы аша Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә тапшырыла.

Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актлары федераль регистрына кертү өчен Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә түбәндәгеләр тапшырыла:

Татарстан Республикасы законнары һәм Татарстан Республикасы Президентының норматив хокукый актлары күчермәләре – Татарстан Республикасы Президенты Аппараты тарафыннан;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актлары күчермәләре – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты тарафыннан;

республика башкарма хакимият органнары норматив хокукый актлары күчермәләре – Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан;

әлеге Указның шушы пунктында һәм 5 пунктының өченче абзацында күрсәтелгән норматив хокукый актларны рәсми бастырып чыгару чыганаклары турында мәгълүматлар – Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан.

5. Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнеше бердәм ведомствоара системасы аша түбәндәгеләрне тапшыруны тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасы законнары күчермәләрен doc яки docx форматларында, әлеге законнарга кул кую өчен алар Татарстан Республикасы Президентына җибәрелгәндә, Татарстан Республикасы Президенты Аппаратына;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының норматив характердагы карарлары күчермәләрен, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актлары федераль регистрына кертү өчен, әлеге актларның федераль законнарда билгеләнгән таләпләргә нигезләнгән форматта рәсми басылып чыккан көненнән җиде көн эчендә Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә.

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына үз актларын 30 көн эчендә әлеге Указга туры китерергә.

7. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының бердәм банкы турында» 2002 елның 8 маендагы ПУ-352 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының

бердәм банкы турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында» 2002 елның 25 ноябрендәге ПУ-1031 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының бердәм банкы турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында» 2005 елның 7 сентябрендәге ПУ-361 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының бердәм банкы турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 9 гыйнварындагы ПУ-1 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының бердәм банкы турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 26 декабрендәге ПУ-687 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының бердәм банкы турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында» 2013 елның 10 августындагы ПУ-751 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының бердәм банкы турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 6 мартындагы ПУ-247 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 8 июлендәге ПУ-585 номерлы Указының 1 пункты.

8. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2017 ел, 28 сентябрь
№ ПУ-861